**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАРЫ

**кырык беренче утырыш**

**28 ноябрь 2024 ел** **№ 154/1** **Алан авылы**

**Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 нче ноябрендәге 115 нче номерлы "Җир салымы турында" карарына үзгәрешләр кертү турында "**

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Теләче муниципаль районы Алан авыл җирлеге Советының 2023 елның 15 нче ноябрендәге 115 нче номерлы "Җир салымы турында" карарына (карарлар редакциясендә 29.07.2024 №138; 01.11.2024 №146) түбәндәге үзгәрешләр кертергә.:

1.1. 3 пунктның «и» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «и) Теләче муниципаль районы Советы карары нигезендә төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать паркы резидентлары яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән төзелгән индустриаль (сәнәгать) парклар дип таныла торган юридик затларга.

«И» пункты нигезендә салым ташламасын куллану хокукын раслый торган документ булып:

- салым чоры ахырына барлык дәрәҗәдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш дәүләт фондларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча недоимкалар булмау;
- ликвидация процессында булмау, шулай ук салым түләүче салым ташламасын белдергән салым чоры ахырына банкротлык процедурасын кузгату түгел;
- Теләче муниципаль районы Советы карары яисә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән төзелгән индустриаль (сәнәгать) парклар нигезендә төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать паркының идарәче оешмасы резиденты статусы турында язма раслау .»;

2. 4.1 Пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә « " 4.1. Салымны һәм салым буенча аванс түләүләрен түләү тәртибе: салымны һәм салым буенча аванс түләүләрен салым түләүче-оешмалар Россия Федерациясе Салым кодексының 397 маддәсе нигезендә түләргә тиеш.».

3. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы А.Р. Зиннатов